Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының кырыгынчы утырышы

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

20 сентябрь, 2019 ел № 99

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Питрәч авыл җирлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге карар чыгарды:

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге территориясендә «2020 елда 18 яшькә җиткән, 1 группа, эшләмәүче 2 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 80 яшькә җиткән гражданнардан, биш һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы студентларыннан һәм мәктәп укучыларыннан кала, аның яшәү урыны Ленино-Кокушкино авыл җирлеге чикләрендә урнашкан, Россия Федерациясенең һәр гражданиныннан 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме? дигән тәкъдим белән чыгарга:

- Олы Бутырка һәм Черемыш авыллары эчендәге юлларны ремонтлау;;
- Салкын Чишмә авылында чишмәне төзекләндерү;
- Ленино-Кокушкино авылында тротуарлар төзү;
- җирлек территориясен төзекләндерү.

Аерым мәсьәләләр буенча акча экономияләнгән очракта, Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитетына референдум тарафыннан билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә,

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) халыкка хәбәр итәргә һәм урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р. Сәйфетдинов